РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«16» октябрь 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 9

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының аерым карарларын юкка чыгару турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә һәм икенче өлешенә һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 26 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 29 июнендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 5 ст. 8 пункты уңаеннан һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Гамәлдән чыгарырга:

«Кайбыч муниципаль районы территориясендә эшчәнлекнең аерым төрләре өчен өстәлгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында» 2012 елның 03 11 декабрендәге 138 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карарын;

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2012 елның 03 декабрендәге 138 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 16 октябрендәге 7 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карарын;

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2012 елның 03 декабрендәге 138 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2016 елның 14 декабрендәге 57 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:// kaybici.tatarstan.ru адресы буенча Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 нче елның 1 нче гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин